КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 4 май г.Казань № 377

Татарстан Республикасында җитештерелә торган продукцияне базарларга чыгару белән идарә итү системасында катнашучылар хезмәттәшлеге регламентын раслау турында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында җитештерелә торган продукцияне базарларга чыгару эшен оештыру турында» 2019 елның 5 мартындагы ПУ-157 номерлы Указын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасында җитештерелә торган продукцияне базарларга чыгару белән идарә итү системасын (алга таба – Система) оештырырга.

2. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасында җитештерелә торган продукцияне базарларга чыгару белән идарә итү системасында катнашучылар хезмәттәшлеге регламентын расларга.

3. Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгын Системаны оештыру һәм аның эшләве өчен җаваплы булган вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

4. Системада республика, Татарстан Республикасы дәүләт заказчылары тарафыннан сатып алына торган продукция турында мәгълүмат биреп тору максатларында:

«Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 93 статьясындагы 1 өлешнең 4 һәм 5 нче пунктлары нигезендә сатып алуларны «Биржа мәйданчыгы» функцияләре агрегаторында (алга таба – Агрегатор) гамәлгә ашырырга.

5. Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына дәүләт катнашындагы оешмаларның (Татарстан Республикасы

дәүләт унитар предприятиеләренең һәм устав капиталында Татарстан Республикасы өлеше булган акционерлар җәмгыятьләренең) Агрегатордан файдалануы турындагы йөкләмәне ирештерергә.

6. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетына тарифларны раслаган вакытта Агрегаторның сатып алу модулендә җайга салына торган эшчәнлекне гамәлгә ашыра торган оешмалар тарафыннан үткәрелгән сатып алулар турындагы мәгълүматларны карап тикшерергә.

7. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Агрегаторда хуҗалык итүче субъектлар ихтыяҗлары һәм сатып алулары турында мәгълүмат урнаштыру буенча оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итүне;

«Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 93 статьясындагы 1 өлешнең 4 һәм 5 нче пунктлары нигезендә Агрегаторның сатып алу модулендә муниципаль заказчылар һәм учреждениеләр тарафыннан сатып алулар үткәрүне тәэмин итүне;

продукция сату һәм аны куллану базарларында Системада Агрегаторның кулланылышын тәэмин итүне;

муниципаль унитар предприятиеләр тарафыннан Агрегаторны файдалану регламентын эшләүне;

буш инвестиция урыннарын локальләштерү мөмкинлеген карауны.

8. Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына квартал саен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары яктылыгында, җирле җитештерүдәге продукцияне сатып алулар һәм сатулар турындагы белешмәләрне кертеп, Агрегатор ресурсларын тулыландыру турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 4 май, 377 нче
карары белән расланды

**Татарстан Республикасында җитештерелә торган продукцияне базарларга чыгару белән идарә итү системасында катнашучылар хезмәттәшлеге**
**РЕГЛАМЕНТЫ**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасында җитештерелә торган продукцияне базарларга чыгару белән идарә итү системасында (алга таба – Система) катнашучылар хезмәттәшлеге регламенты яңа эш урыннары оештыру өчен яңа җитештерүләр булдыру һәм гамәлдәге җитештерүләрне үстерү, тулаем территориаль продуктны һәм тулаем төбәк продуктын арттыру буенча бурычларны хәл итү максатларында эшләнде.

1.2. Бу Регламент белән Системада катнашучыларның үзара хезмәттәшлек итү тәртибе җайга салына, ул товар җитештерүчеләрнең кооперация элемтәләрен анализлауны һәм исәпкә алуны, предприятиеләргә үз җитештерү, хуҗалык һәм маркетинг эшчәнлеген нәтиҗәле планлаштырырга мөмкинлек бирә торган мәгълүмат коммуникацияләре системасын булдыруны үз эченә ала.

## II. Терминнар, билгеләмәләр һәм кыскартылмалар

2.1. «Биржа мәйданчыгы» функцияләре агрегаторы (алга таба – Система Агрегаторы) – сатып алу модулен, исәпкә алу ресурсларын, аналитик, мәгълүмати һәм башка ресурсларны, Татарстан Республикасының күзәтелә торган базарларында җитештерелә һәм кулланыла торган продукция реестрларын, җитештерү күләмнәре, товарлар сатып алу, эшләр башкару һәм хезмәт күрсәтүләр номенклатурасы һәм күләмнәре турындагы мәгълүматларны үз эченә ала торган һәм тәртипкә салынган мәгълүмат системасы. Агрегаторның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге электрон адресы – bp.zakazrf.ru.

2.2. Сатып алу модуле – сатучының һәм сатып алучының электрон элемтә каналлары аша үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә торган оештыру ягыннан, мәгълүмати һәм техник яктан чишелешләрнең программа-аппарат комплексы.

2.3. Мәгълүмат – товар җитештерүчеләрнең, чимал, материаллар һәм комплектлау әйберләре белән тәэмин итүчеләрнең продукцияләре номенклатурасы, контрагентлары һәм кооперация элемтәләре яктылыгында күзәтелә торган куллану базарларында продукцияләр сатып алу һәм сату күләмнәре турында структурлаштырылган мәгълүматлар.

2.4. Система администраторы – Республика маркетинг үзәге – Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән, Электрон сәүдә

мәйданчыгын (www.zakazrf.ru) администраторлаштыруны, Агрегатор ресурсларының эшләвен, Татарстан Республикасының электрон сәүдә мәгълүмат системасын (www.tattis.ru) куллануны тәэмин итә торган оешма.

2.5. Система яраштыручысы – Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы, Системаны оештыру һәм аның эшләве өчен җаваплы һәм вәкаләтле орган.

2.6. Системада катнашучылар – идарә итү карарларын формалаштыручы һәм кабул итүче, шулай ук мәгълүмат белән тәэмин итүче һәм аны кулланучы субъектлар, аның составына түбәндәгеләр керә: Система яраштыручысы, Система администраторы, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасындагы муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары).

2.7. Буш инвестиция урыннары – Татарстан Республикасында таләп ителә торган, аның территориясендә җитештерелми яки кече күләмнәрдә җитештерелә торган продукция.

## III. Системада катнашучыларның үзара хезмәттәшлеге тәртибе

### 3.1. Система яраштыручысы

Система яраштыручысы Система оештыруны һәм аның эшләвен тәэмин итә, шул исәптән:

3.1.1. Мәгълүмат нигезендә оешмалар тарафыннан продукция сату һәм сатып алу динамикасына анализ ясауны гамәлгә ашыра, җитештерүне локальләштерү мөмкинлеген бәяләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары, шулай ук хуҗалык итүче субъектлар белән эш оештыра;

3.1.2. Продукция куллану буенча күзәтелә торган базарлар исемлеген формалаштыра һәм раслый;

3.1.3. Системаның эшләвен җайга сала торган гамәлдәге норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр әзерли;

3.1.4. Җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлекне оештыра;

3.1.5. Система администраторы тарафыннан тапшырыла торган мәгълүмат нигезендә Система эшләве кысаларында Татарстан Республикасының тармак министрлыклары һәм ведомстволары, җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенщ анализ үткәрә һәм тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрә;

3.1.6. Җирле үзидарә органнарында яңа җитештерүләр һәм яңа эш урыннары булдыруны тасвирлый торган индикаторларны җирле үзидарә органнары (шәһәр җирлекләре) эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырыла торган мәгънәләренә ирешү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр советы һәм Татарстан Республикасының муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында төзелгән килешүләргә кертү буенча тәкъдимнәр формалаштыра.

**3.2. Система дминистраторы**

Система администраторы түбәндәге функцияләрне башкара:

3.2.1. Басылып чыккан Мәгълүматка Атналык режимда анализ үткәрә һәм аның нигезендә буш инвестиция урыннары исемлеген, базарлар сыйдырышлыгын һәм бәя параметрларын һ.б. формалаштыра;

3.2.2. Системада катнашучылар тарафыннан җибәрелә торган Мәгълүматны кабул итүне, эшкәртүне һәм актуаль хәлдә тотуны тәэмин итә;

3.2.3. Ай саен Система администраторы ресурсларында басылып чыккан Татарстан Республикасында җитештерелә торган продукция күләмнәре турында, Татарстан Республикасы оешмалары һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары тарафыннан сатыла һәм сатып алына торган продукция динамикасы турында, Татарстан Республикасында теркәлмәгән товар позицияләре турында аналитик хисаплар (бу хасапларга бәя параметрларын да кертеп) төзи һәм аларны Система яраштыручысына кертә, шулай ук әлеге мәгълүматны электрон мәгълүматлар базасын (ул архив мәгълүматларын алып баруны һәм эзләүне күздә тота) формалаштыру һәм актуаль хәлдә тоту өчен Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетына җибәрә;

3.2.4. Система администраторының ресурсларны тулыландыру буенча регламент функцияләрен үтәүгә комачаулый торган сәбәпләргә ясалган анализны Система яраштыручысына җибәрә;

3.2.5. Агрегаторның сатып алу модуле аша җитештерелә торган продукцияне сатып алу мониторингын гамәлгә ашыра;

3.2.6. Система яраштыручысы адресына продукция сатуның һәм куллануның билгеле бер базарларында Агрегаторның сатып алу модулен куллану өлкәсен киңәйтү турында тәкъдимнәр әзерли;

3.2.7. Система администраторы тарафыннан Агрегатор ресурсларын тулыландыру һәм файдалану турында адреслы мәгълүмат әзерли һәм аларны баланс комиссияләрен үткәрү өчен материаллар составына кертә.

**3.3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары түбәндәге функцияләрне башкара:

3.3.1. «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 93 статьясындагы 1 өлешнең 4 һәм 5 нче пунктлары нигезендә сатып алуларны гамәлгә ашырганда Агрегатор системасын куллануны тәэмин итә;

3.3.2. Системаны Мәгълүмат белән тулыландыру һәм сатып алу процедураларын конкурентлы нигездә тәэмин итү максатларында, төзелгән дәүләт контрактларын үтәү өчен кирәкле продукция сатып алу өчен үтәүчеләр (подрядчылар, тәэмин итүчеләр) тарафыннан Агрегаторның сатып алу модулен куллану турындагы пунктны дәүләт контрактлары проектларына кертә;

3.3.3. Буш инвестиция урыннары турындагы, Татарстан Республикасы территориясендә җитештерүне локальләштерү турындагы, шулай ук җитештерелә

торган продукция күләмнәрен аны куллану базарлары сыйдырышлыгына карап арттыру турындагы мәгълүмат нигезендә тәкъдимнәр формалаштыра;

3.3.4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Икътисадый эшчәнлек төрләре буенча министрлык ведомствосы буйсынуындагы оешмаларның (теләсә кайсы оештыру-хокукый рәвешендәге) финанс-хуҗалык эшчәнлеген карап тикшерү буенча Татарстан Республикасы тармак министрлыкларының баланс комиссиясен әзерләү һәм үткәрү стандартын раслау турында» 2016 ел, 3 май, 276 нчы карары нигезендә тармак баланс комиссияләрендә җавап бирә торган өлкә предприятиеләрендәге эшләрнең торышын карап тикшергәндә һәм аларның финанс тотрыклылыгын бәяләгәндә тармак баланс комиссияләре утырышының көн тәртибенә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын эре предприятиеләр эшчәнлегенә җәлеп итү, продукция сату һәм куллану буенча күзәтелә торган базарларда Агрегаторны куллану мәсьәләсен мәҗбүри итеп кертә.

---